*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге “Балачак” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*



# Чишмә башы



*Декабрь,*

*№ 2*





***Ата-аналар һәм балалар өчен кызыклы мәгълүматлар***


## "Кышкы рәхәтлек"

Яңалык сөйлим сезгә:
Кыш килде бит әле безгә!
Ябалак-ябалак ява кар,
Бездә чиксез шатлык бар!
Тылсымланды бар дөнья,
Чумды сихри аклыкка.
Йомшак карда тәгәрибез,
Чыдап булмый шатлыкка!
Агачлар ак шәл ябынды,
Бизәкләнде тәрәзә:
Табигать иң оста рәссам,
Аңа бик зур дәрәҗә!
Яңа елга өй янына
Ясап куйдык Кар бабай.
Аның белән җитәкләшеп
Кар кызы тора, малай!

Гөлчирә Нәҗметдинова

## Кыш турында сынамышлар

* Кышын кар күп булса, җәй яңгырлы булыр.
* Кыш көне яңгыр яуса, икмәк булыр.
* Кышын томан булса, җәен юкәдә бал була.
* Утын сызгырса, көн суытыр.
* Гыйнварның унында бәс төшсә, җәй яңгырлы килер.
* Моржадан чыккан төтен туры булып өскә менсә, көн аяза, суыта. Әгәр төтен җиргә ятса, көн җылыта.
* Яңа елда ябалак кар яуса, аннан соң һава җылы, юеш булыр.
* Әгәр кар вак кына бөртекле, сирәк кенә төшкәләсә, бик озак суык булыр.
* Кошлар кар өстенә төшсә, көн җылыта.
* Кыш көне мәче һәр җирдә тырнаса, буран булыр.
* Чыпчыклар кыш көне җыелышып бер урында чыркылдашсалар, җылы булып кар явар.
* Колак кычытса, кышын буран булыр.
* Кар күп булса, җәйдә иген-печән уңар.
* Кыш көне кырдагы үлән кайсы якка таба бөгелсә, җәй көне ашлык шул якка таба бөгелер.



# “Кыш бабай остаханәсе” күргәзмәсе













# *Балаларның, тәрбиячеләрнең уңышлары*











































1993 елдан 3 декабрьдә Халыкара инвалидлар көне билгеләп үтелә. Инвалидлар – алар көчле ихтыярлы, батыр, дөньяны аерым күрүче, эчке яктан бай кешеләр. Аларның берсе хәрәкәт итүдә чикләнгән, икенчеләре дөньяның төсләрен күрү, аның күптөрле тавышларын ишетү мөмкинлегеннән мәхрүм.
Шул уңайдан балалар бакчаларында да төрле чаралар үткәрелә. Без балалар белән шул темага әңгәмә үткәрдек. "Җиде таҗлы чәчәк" мультфильмын карап, нәтиҗә ясадык. Максатыбыз - үзеңнең сәламәтлегеңне саклау, инвалидларга карата кайгыртучанлык һәм хөрмәт тәрбияләү.

Мәктәп белән дәвамчанлык эш планы нигезендә мәктәпкә экскурсия оештырылды. Балалар мәктәп китапханәсе, музее, технология кабинетлары белән таныштылар. Экскурсия бик кызыклы, эчтәлекле булды.










Бакчабызда "Тәрбияле бала - ил терәге" темасы буенча ата-аналар җыелышы булып узды. Җыелышта Наласа авылы участок инспекторы Ибраһимов Альмир Алмаз улы, шәфкать туташы мөдире Гәрәева Зәринә Рифат кызы да катнаштылар.















Яңа ел һәр йортта, һәр гаиләдә көтеп алынган бәйрәм. Яңа ел һәрвакыт могҗиза, маҗаралар һәм гаҗәеп үзгәрешләр бүләк итә.

Балалар бакчасында бәйрәмгә әзерлекне алдан ук башладык.: инсценировка төзедек, костюмнар әзерләдек, бергәләп залны бизәдек.Бәйрәмгә кунаклар бик күп килде.

Кыш бабай, Кар кызы килү белән җыр һәм бию, уен - көлке, чын бәйрәм башланды.Барлык балалар рәхәтләнеп үзләренең талантларын күрсәттеләр: биеделәр, әйлән - бәйлән әйләнделәр, шигырьләр сөйләделәр, җырлар җырладылар. Кыш бабай кулыннан балаларга бирелгән бүләкләр шатлык хисләре уятты. Балалар күчтәнәчләрне рәхмәт әйтеп алдылар.

Бәйрәмдә әкият геройлары булып киенеп катнашкан бакча хезмәткәрләренә дә бик зур рәхмәт.

Бәйрәм бик күңелле , шатлыклы узды, бик матур тәэсирләр калдырды.

Яңа 2025 нче ел илебезгә тынычлык, шатлык, куанычлар гына алып килсен иде. Барлык кешеләр дә үз туганнары белән исән - сау яшәсеннәр.




Татарстанда фәнни-технологик үсеш һәм Россияда фән һәм технологияның унъеллыгы уңаеннан бакчабызда план буенча әңгәмәләр уздырылды. Балалар һәм эти-әниләр белән берлектә ясаган эшләрдән күргәзмә булдырылды. Барлык катнашучыларга рәхмәтебезне белдерәбез. Бик кызыксынып,сокланып карый торган эшләр. Тырышканыгыз , безгә эшебездә булышканыгыз өчен бик зур рәхмәт!

















**“Робот-лампа - Роберт”**
Фән һәм технологик үсеш
Елы игълан ителгәч,
Тәрбияче апабыз
Бирде бит шундый киңәш:
- Ягез әле, балалар,
Без дә тырышып карыйк.
Төрледән-төрле, кызыклы
Кул эшләрен без ясыйк.
Кайттым, әйттем әниемә:
- Әни, мин робот ясыйм.
Ниләр кирәк буласын
Хәзер үк барлый башлыйм
Минем кararны ишеткәч,
Аптырап куйды әни:
- Шул гына җитмәгән иде,
Уйлап таптың тагын ни?!
Әйе, әнием, дөрес әйтә!
Ни генә эшләнмәде:
Җимлек, сыерчык оясы,
Чигүле мендәрләре.
Төрле әкият герое –
Калмады шул берсе дә.
Инде хәзер робот ясыйм
Күрерсез әле менә.
Әти белән сөйләштек тә,
Тотындык аннан эшкә.
Кызып-кызып эшкә чумгач,
Йоклап киткәнмен менә.
Иртән күзләремне ачсам,
Робертым инде әзер.
Бер эштән дә курыкмыйбыз
Әтием белән хәзер.

(Хәмзәне яратучы апасы Ләйлә Фәхриева)







***Газетаны оештыручы һәм баш мөхәррир:*** *Гафурова Р.А., Галиуллина А.Ф.*
***Редколлегия әгъзалары:*** *Хөсәенова Р.Н., Шагиева А.К., Гафурова Э.Р.*
*Адрес: 422018 ТР,Арча районы, Наласа авылы, Үзәк урам, 76 йорт*